Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №X-10**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 28 июне

Цифрлы финанс активлары һәм цифрлы хокуклар турында мәгълүматлар бирү хакында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар бирү хакындагы аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының "Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында"гы 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Билгеләргә: 2021 елның 30 июненә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 17 февралендәге L-2 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәт вазыйфалары Исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын (аларны биләү коррупция куркынычы белән бәйле) биләүгә дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар аларга билгеләнгәндә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә тиеш, Россия Федерациясе Президентының "Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләр турында һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча тапшырыла торган мәгълүматлар белән бергә үзләренә, ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларына караган цифрлы финанс активлары, бер үк вакытта цифрлы финанс активларын һәм башка цифрлы хокукларны, утилитар цифрлы хокукларны һәм цифрлы валютаны (алар булганда) үз эченә алган цифрлы хокуклар турында Россия Федерациясе Президентының "Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чаралары хакында"гы

2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указына бирелгән 1 нче кушымтага ярашлы форма буенча хәбәрнамәләр тапшыралар.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырып игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Ф.Г. Әхмәтҗанова